ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2018 Баулы шәһәре № 57

Баулы муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 17 июлендә кабул ителгән 148нче санлы «Баулы муниципаль районы Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш тәртибен раслау турында»гы карары белән расланган Баулы муниципаль районы Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 27 ноябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы 355-ФЗ Федераль закон нигезендә

КАРАРИТӘМ:

Баулы муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 17 июлендә кабул ителгән 148нче санлы «Баулы муниципаль районы Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш тәртибен раслау турында»гы карары белән расланган Баулы муниципаль районы Советы аппаратында гражданнар мөрәҗәгатьләрен

карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча эш тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка тикшерүгә җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгән көннән җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.»;

1.10 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«2017 елның 27 ноябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы № 355-ФЗ Федераль законның 10нчы статьясы 4 өлеше нигезендә, Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгатькә җавап Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырылган булса, мөрәҗәгать җибәргән гражданинга мөрәҗәгатьне теркәгән көннән җиде көн эчендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Баулы муниципаль районы сайты адресы җибәрелә, шул ук вакытта суд карарына шикаятьле мөрәҗәгать кире кайтарылмый.»;

2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.15. Язма мөрәҗәгатькә җавап район башлыгы, район башлыгы урынбасары яки Совет аппараты бланкында әзерләнә һәм җитәкче яисә аңа вәкаләтле башка зат тарафыннан кул куела.

Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатькә җавап күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә кергән мөрәҗәгать күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Моннан тыш, Совет аппаратына яисә вазыйфаи затка билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылучы тәкъдим, гариза яисә шикаять кергәндә,

аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата суд карарына шикаять белдерелә торган мөрәҗәгатькә, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, җавап, 2006 елның 2 маенда кабул ителгән «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль законның 6 статьясы 2 өлеше таләпләрен үтәп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Баулы муниципаль районы сайтында (http://bavly.tatarstan.ru) урнаштырылырга мөмкин.

Ике һәм аннан күбрәк зат мөрәҗәгатьләренә (күмәк мөрәҗәгать) җавап аңа имза салган беренче зат исеменә (әгәр мөрәҗәгатьтә конкрет кеше әйтелмәсә) яисә аерым очракларда - мондый мөрәҗәгатьне имзалаган һәр кешегә җибәрелә.».

Баулы муниципаль районы
Башлыгы

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Р.Х. Гатиятуллин